


**Алабуга муниципаль районы « 1 нче гимназия» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе**

# Сүз аша телгә мәхәббәт тәрбияләү (Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст)


**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Нигъмәтуллова Рәмзия Нурмөхәммәт кызы**

**Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст**

# Сүз

**Эчке ягы (*мәгънәсе*)**

**Тышкы ягы *(материаль яңгырашы)***

**Сүз** һәр телнең үз фонетик закончалыкларына таянып барлыкка килә, хәтта башка телләрдән кабул ителгән тәкъдирдә дә, күпчелек очракта кабул иткән телнең шушы закончалыкларына буйсынып, яңгырашы ягыннан үзгәртелә.

Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст

**Катлаулы һәм семантик, грамматик, стилистик төсмерләргә бай универсаль берәмлек булган сүзгә лингвистик анализ бары тик *контекст* аша гына башкарыла ала.**

***Контекст – contextus* сүзе «бәйләү, бәйләнеш» төшенчәсен аңлата.**

**Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст**

**Карта**

**җир сурәтенең сызымы**

**?**

**ат картасы**




**Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст**

***«Капка»*** сүзен мәгънәле кисәкләргә бүләбез

*кап* - исем (шырпы кабы), берлек санда, юнәлеш килешендә, (сүзбәйләгеч кушымча -*ка*) уртаклык исеме .

Әгәр «ворота» турында сүз бара икән, аның тамыры *кап* була һәм ул «каплау, ачылып торган түгел» идеясен (мотивын) чагылдыра, ул чагында -*ка* – сүзьясагыч кушымча.



Әгәр без **контекст** белән эш итмәсәк, сүзләр кебек үк кушымчаларның да үзара омоним булырга мөмкинлеген исәпкә алмасак, ялгыш нәтиҗәләр китереп чыгарачакбыз.

# Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст

## Кушымча – абстракт төшенчә.

*җыен* (*җый-ын*)*, ю-ын-, табын-,* мисалларында карап торышка бер генә кушымча бар кебек: -*ын*.

## Ләкин


а) беренчесендә *җый*- фигыленнән исем ясалган, димәк, беренче *-ын* кушымчасы – фигыльдән исем ясагыч;

б) икенче мисалда (*юын*-), тагын бер кушымча килгән, ул – модальлек, *ю*-фигыленең кайтым юнәлеше күрсәткече;

в) өченче мисалдагы *-ын* – *тап*- ‘находить’ фигыленнән яңа фигыль берәмлеге ясаган: *табыну* ‘преклоняться’.

**Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст**

Морфологиядә аерым сүзгә анализ контексттан тыш кына, гомумән, башкарыла алмый.



*Китап*

*Китап* өстәлдә тора җөмләсендәге бу исем эшнең башкаручысын (субъектын) белдерә, җөмләнең иясе;


*Китап* бастырып чыгардылар җөмләсендәге әлеге исем объект мәгънәсен белдерә, шулай ук җөмләнең иясе була;

*Китап* укысаң, белемең артыр җөмләсендәге *китап,* туры объектны белдерә, ул - җөмләнең туры тәмамлыгы;

*Китап* тышына язарга ярамый мисалындагы *китап* билгесез иялек мәгънәсендә кулланылган һәм ул бу җөмләнең аергычы.

**Татар теле дәресләрендә лингвистик анализ һәм контекст**

Шулай итеп, аерым параграфларда бирелгән теоретик тел материалын кабатлау, йомгаклау һәм контроль эш дәресләрендә тиешле нәтиҗәләр бирә алырлык камәлгә җиткерү турында кайгыртабыз икән, һичшиксез, тел күренешләренең табигый даирасе булган контекст мәҗбүри рәвештә искә алынырга тиеш.



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!